ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАШКИЧУЙСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.18а, д.Малые Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 18а йорт, Кече Урыссу авылы,
423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz @tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

***№ 29***     **«29» апреля 2019 г.**

Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге
Башкарма комитеты баш хисапчылары
һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәт вазифаларына
кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру
һәм аны түләү шартлары турында

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетның баш хисапчыларына һәм хисапчыларына (муниципаль хезмәт вазифаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм хезмәтләре өчен түләүне тәртипкә салу максатларында карар бирә:

1. Расларга:

Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетының баш хисапчылары һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында Нигезләмәне.

2. Әлеге карар нигезендә билгеләнә торган хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләме, хезмәткәрләр вазыйфаи бурычлары күләмен һәм алар тарафыннан шул ук квалификациядәге эш башкарылганда, аларга хезмәт хакы 2019 елның 31 мартына түләнә торган хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.

3. Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 23 маендагы «Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитеты хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында " 15 санлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

5. Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетының баш хисапчылары һәм хисапчылары вазифалары исемлеген (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) әлеге карарга туры китерүне тәэмин итәргә;

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Валеев.

Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге Башкарма
комитеты карары белән расланды
“29” май 2019 ел №29

**Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетының баш хисапчылары һәм хисапчыларының хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары (Ютазы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре вазифаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) турында Нигезләмә**

1.Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетының баш хисапчылары һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) (алга таба – хисапчылар) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында әлеге Нигезләмә хисапчылар эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлый һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәрен һәм аларны түләү шартларын билгели.

2. Хисапчыларның хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, матди ярдәм һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән тора.

3. Хисапчыларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазифа | Халык саны булган муниципаль берәмлек Башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 мең кешедән артык |
| Баш хисапчы | 15 700 сум | 17 000 сум |
| Хисапчы | - | 14 500 сум |

Муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары штат расписаниесенә хисапчы (бухгалтер) вазыйфасын кертү шарты булып муниципаль берәмлекнең халык саны 3,5 меңнән артык кеше булуы тора.

3. Хисапчыларга билгеләнә:

1) тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен түбәндәге күләмнәрдә өстәмә түләү:

| Эш стажы булганда | Ай саен өстәмә түләү, процент |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә;

3) еллык түләүле отпуск биргәндә, вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә бер тапкыр түләнелә торган акча;

Әгәр хисапчыларга календарь ел дәвамында еллык түләүле ял бирелмәсә, бер тапкыр түләнә торган акча аңа декабрьдә, эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә түләнелә һәм, эштән азат ителгән очракта – соңгы эш көненнән соңламыйча.

Беренче эш елында еллык түләүле отпуск биргәндә хисапчыларга бер тапкыр түләнелә торган акча календарь елында эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә түләнелә. Эшләнгән вакыт агымдагы календарь елда эшли башлаган көннән календарь елның 31 декабренә кадәрисәпләнә.

4) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм;

5) эш буенча премия *(премия түләү шартлары, даимилеге, күләме гамәлдәге хезмәткә түләү шартларыннан чыгып билгеләнә).*

4. Хисапчыларның еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула белән исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} \mathrm{P} * (1 + t);$$

биредә:

$FOT$ – хисапчыларның еллык хезмәт хакы фонды;

$O_d$ – хисапчының вазыйфаи окладын түләү өчен бер айга акча суммасы;

$0{,}3 * O_d$ - тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү, эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү, акчалата бүләкләү, еллык түләүле отпуск, матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр түләнә торган түләү өчен акча суммасы;

Р – хисапчыларның еллык премиаль фонды (әлеге Нигезләмәнең 3 пунктындагы 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә);

$n$ – хисапчыларның штат саны;

$k$ - 12 ай;

$t$- хезмәт өчен түләү буенча хисаплаулар.